# ЗАКОН
## РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «Об Общественной палате Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
25 сентября 2015 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 14 октября 2005 года № 103-ЗРТ «Об Общественной палате Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 10 (I часть); 2007, № 10; 2008, № 11 (III часть); 2009, № 12 (I часть); 2011, № 10 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 11 (I часть) следующие изменения:

1) часть 2 статьи 1 дополнить словами «, а также общественных советов муниципальных образований Республики Татарстан (далее – общественные советы муниципальных образований)»;

2) в статье 4:
а) пункт 1 после слова «организаций» дополнить словами «, общественных советов муниципальных образований»;
б) пункт 2 после слова «организаций» дополнить словами «, общественных советов муниципальных образований»;

3) статью 5 изложить в следующей редакции:
«Статья 5. **Состав Общественной палаты**

1. Общественная палата формируется в составе 70 человек.
2. Новый состав Общественной палаты утверждается соответственно Президентом Республики Татарстан в количестве 20 человек, Государственным Советом Республики Татарстан в количестве 20 человек и Общественной палатой действующего состава в количестве 30 человек.

3. Лица, ранее являвшиеся членами Общественной палаты двух составов Общественной палаты, непосредственно предшествовавших вновь утверждаемому составу Общественной палаты, не могут быть членами нового состава Общественной палаты.»;

4) статью 6 изложить в следующей редакции:

«Статья 6. **Порядок выдвижения кандидатов в члены Общественной палаты**

1. Правом выдвижения кандидатов в члены Общественной палаты обладают организации, осуществляющие свою деятельность как на всей территории Республики Татарстан, так и на территории отдельных районов и городов, в том числе территориальные отделения всероссийских и межрегиональных организаций, зарегистрированные в установленном законодательством порядке не позднее чем за один год до дня истечения полномочий действующего состава Общественной палаты, а также общественные советы муниципальных образований.

2. Организация, изъявившая желание выдвинуть своего представителя в Общественную палату, в месячный срок со дня официального опубликования в средствах массовой информации информационного сообщения о формировании нового состава Общественной палаты направляет соответственно Президенту Республики Татарстан, Государственному Совету Республики Татарстан или Общественной палате действующего состава заявление о включении своего представителя в состав Общественной палаты, оформленное решением руководящего коллегиального органа организации. К заявлению прикладываются копия свидетельства о государственной регистрации организации, решение полномочного в соответствии с уставом организации органа о выдвижении кандидата в члены Общественной палаты, сведения о кандидате и письменное согласие кандидата на участие в работе Общественной палаты, информация о деятельности организации.

3. Общественный совет муниципального образования, изъявивший желание выдвинуть своего представителя в Общественную палату, в месячный срок со дня официального опубликования в средствах массовой информации информационного сообщения о формировании нового состава Общественной палаты направляет Общественной палате действующего состава заявление о включении своего представителя в состав Общественной палаты, оформленное решением общественного совета муниципального образования. К заявлению прикладываются копия нормативного правового акта о создании общественного совета муниципального образования, решение общественного совета муниципального образования о выдвижении кандидата в члены Общественной палаты, сведения о кандидате и письменное согласие кандидата на участие в работе Общественной палаты.

4. При выдвижении представителя в состав Общественной палаты вместо члена Общественной палаты, полномочия которого прекращены досрочно, организация, изъявившая желание выдвинуть своего представителя в Общественную палату, в месячный срок со дня официального опубликования в средствах массовой информации информационного сообщения о выдвижении кандидатов в члены Общественной

палаты направляет заявление о включении своего представителя в состав Общественной палаты в орган, утвердивший члена Общественной палаты, полномочия которого прекращены. При досрочном прекращении полномочий члена Общественной палаты, утвержденного предыдущим составом Общественной палаты, заявление о включении своего представителя также вправе направить общественный совет муниципального образования.

5. Информационное сообщение о начале формирования нового состава Общественной палаты публикуется Советом Общественной палаты в официальных средствах массовой информации не позднее чем за три месяца до истечения срока полномочий действующего состава Общественной палаты.»;

5) часть 1 статьи 7 после слова «организаций» дополнить словами «, общественных советов муниципальных образований»;

6) в части 1 статьи 9 слова «три года» заменить словами «четыре года»;

7) дополнить статьей $9^{1}$ следующего содержания:

«Статья $9^{1}$. **Обновление состава Общественной палаты**

1. По истечении первых двух лет полномочий действующий состав Общественной палаты может быть обновлен по решению Общественной палаты.

2. В целях настоящей статьи под обновлением состава Общественной палаты понимается досрочное прекращение полномочий части ее членов. Количество членов Общественной палаты, полномочия которых прекращаются досрочно в связи с обновлением состава, определяется Общественной палатой самостоятельно. При этом каждый из списков членов Общественной палаты, утвержденных Президентом Республики Татарстан, Государственным Советом Республики Татарстан, Общественной палатой предыдущего состава, могут быть изменены не более чем на четверть.

3. Решение об обновлении состава Общественной палаты принимается Общественной палатой по предложению Совета Общественной палаты с учетом эффективности работы членов Общественной палаты. В решении указываются члены Общественной палаты, полномочия которых прекращаются досрочно в связи с обновлением состава.»;

8) в статье 13:

а) в части 1:

дополнить пунктом $1^{1}$ следующего содержания:

«$1^{1}$) принятия в отношении члена Общественной палаты решения о досрочном прекращении его полномочий в соответствии со статьей $9^{1}$ настоящего Закона;»;

дополнить пунктом $8^{1}$ следующего содержания:

«$8^{1}$) отзыва общественным советом муниципального образования, выдвинувшим его кандидатуру;»;

б) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. В случае досрочного прекращения полномочий члена Общественной палаты выдвинувшая его кандидатуру организация либо выдвинувший его кандидатуру общественный совет муниципального образования могут в течение семи дней внести предложение по новой кандидатуре в орган, утвердивший члена Общественной палаты от данной организации либо общественного совета муниципального образования, за исключением прекращения полномочий по основаниям, указанным в пунктах $1^1$, 2, 7, 8 и $8^1$ части 1 настоящей статьи.»;

в) в части 5 слово «могла» заменить словами «, общественный совет муниципального образования могли»;

9) статью 14 после слова «Организация» дополнить словами «, общественный совет муниципального образования», после слова «организация» дополнить словами «, общественный совет муниципального образования»;

10) в части 2 статьи 15:

а) пункт 10 после слова «организаций» дополнить словами «, общественных советов муниципальных образований»;

б) пункт 11 изложить в следующей редакции:

«11) порядок подготовки и публикации ежегодного доклада Общественной палаты о состоянии и развитии институтов гражданского общества в Республике Татарстан;»;

в) дополнить пунктом $11^3$ следующего содержания:

«$11^3$) критерии и порядок оценки эффективности работы членов Общественной палаты;»;

11) в части 4 статьи 16 слова «не менее двух третей» заменить словами «более половины»;

12) статью 23 изложить в следующей редакции:

«Статья 23. **Ежегодный доклад Общественной палаты о состоянии и развитии институтов гражданского общества в Республике Татарстан**

1. По окончании календарного года Общественная палата готовит доклад о состоянии и развитии институтов гражданского общества в Республике Татарстан и публикует его в официальных средствах массовой информации, а также размещает на сайте Общественной палаты в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет».

2. Ежегодный доклад Общественной палаты направляется Президенту Республики Татарстан, Государственному Совету Республики Татарстан, Кабинету Министров Республики Татарстан, а также по решению Общественной палаты может быть направлен иным государственным органам и органам местного самоуправления.

3. С ежегодным докладом председатель Общественной палаты выступает на заседании Государственного Совета Республики Татарстан.».

**Статья 2**

Положение части 3 статьи 5 Закона Республики Татарстан от 14 октября 2005 года № 103-ЗРТ «Об Общественной палате Республики Татарстан» (в редакции настоящего Закона) не распространяется на правоотношения, возникающие при формировании первых двух составов Общественной палаты Республики Татарстан после вступления в силу настоящего Закона.

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
9 октября 2015 года
№ 80-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 10 (I өлеш); 2007, № 10; 2008, № 11 (III өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешендә “(алга таба – оешмалар)” сүзләреннән соң “, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре иҗтимагый советларының (алга таба – муниципаль берәмлекләр иҗтимагый советлары)” сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяда:
а) 1 пунктта “оешмаларның” сүзеннән соң “, муниципаль берәмлекләр иҗтимагый советларының” сүзләрен өстәргә;
б) 2 пунктта “оешмаларның” сүзеннән соң “, муниципаль берәмлекләр иҗтимагый советларының” сүзләрен өстәргә;

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“5 статья. **Иҗтимагый палата составы**

1. Иҗтимагый палата 70 кеше составында төзелә.
2. Иҗтимагый палатаның яңа составы тиешенчә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан 20 кеше, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 20 кеше һәм гамәлдәге составтагы Иҗтимагый палата тарафыннан 30 кеше исәбеннән раслана.

3. Иҗтимагый палатаның яңа раслана торган составына кадәрге Иҗтимагый палатаның рәттән ике составында Иҗтимагый палата әгъзалары булган затлар яңа составтагы Иҗтимагый палата әгъзалары була алмыйлар.";

4) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"6 статья. **Иҗтимагый палата әгъзалары урыннарына кандидатлар күрсәтү тәртибе**

1. Иҗтимагый палата әгъзалары урыннарына кандидатлар күрсәтү хокукына Татарстан Республикасының бөтен территориясендә, шулай ук аерым районнар һәм шәһәрләр территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар, шул исәптән бөтенроссия һәм төбәкара оешмаларның гамәлдәге составтагы Иҗтимагый палата вәкаләтләре тәмамланган көнгә кадәр кимендә бер ел кала законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән территориаль бүлекчәләре, шулай ук муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый советлары ия була.

2. Иҗтимагый палатага үз вәкилен күрсәтергә теләк белдергән оешма Иҗтимагый палатаның яңа составы төзелү турында мәгълүмати хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә тиешенчә Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына яисә гамәлдәге составтагы Иҗтимагый палатага оешманың җитәкче коллегиаль органы карары белән рәсмиләштерелгән Иҗтимагый палата составына үз вәкилен кертү турында гариза җибәрә. Гаризага оешманы дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның күчермәсе, оешма уставы нигезендә вәкаләтле булган органның Иҗтимагый палата әгъзасы урынына кандидат күрсәтү турында карары, кандидат турында белешмәләр һәм кандидатның Иҗтимагый палата эшендә катнашуга язма ризалыгы, оешма эшчәнлеге турында мәгълүмат теркәп бирелә.

3. Иҗтимагый палатага үз вәкилен күрсәтергә теләк белдергән муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы Иҗтимагый палатаның яңа составы төзелү турында мәгълүмати хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә гамәлдәге составтагы Иҗтимагый палатага муниципаль берәмлек иҗтимагый советының карары белән рәсмиләштерелгән Иҗтимагый палата составына үз вәкилен кертү турында гариза җибәрә. Гаризага муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советын төзү турындагы норматив хокукый актның күчермәсе, муниципаль берәмлек иҗтимагый советының Иҗтимагый палата әгъзасы урынына кандидат күрсәтү турында карары, кандидат турында белешмәләр һәм кандидатның Иҗтимагый палата эшендә катнашуга язма ризалыгы теркәп бирелә.

4. Иҗтимагый палатаның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган әгъзасы урынына Иҗтимагый палата составына вәкил күрсәткәндә, Иҗтимагый палатага үз вәкилен күрсәтергә теләк белдергән оешма үз вәкилен Иҗтимагый палата составына кертү турындагы гаризасын Иҗтимагый палата әгъзалары урыннарына кандидатлар күрсәтү турында мәгълүмати хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыккан көннән алып бер ай эчендә Иҗтимагый палатаның вәкаләтләре туктатылган әгъзасын раслаган органга җибәрә. Иҗтимагый палатаның элекке

составтагы Иҗтимагый палата тарафыннан расланган әгъзасының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы шулай ук үз вәкилен кертү турында гариза җибәрергә хокуклы.

5. Иҗтимагый палатаның яңа составын төзи башлау турында мәгълүмати хәбәр Иҗтимагый палата Советы тарафыннан гамәлдәге составтагы Иҗтимагый палатаның вәкаләтләр чоры тәмамланырга кимендә өч ай кала рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.";

5) 7 статьяның 1 өлешендә "оешмалар" сүзеннән соң ", муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый советлары" сүзләрен өстәргә;

6) 9 статьяның 1 өлешендә "өч ел" сүзләрен "дүрт ел" сүзләренә алмаштырырга;

7) түбәндәге эчтәлекле $9^1$ статья өстәргә:

"$9^1$ статья. **Иҗтимагый палата составын яңарту**

1. Иҗтимагый палатаның гамәлдәге составы, вәкаләтләренең беренче ике елы узганнан соң, Иҗтимагый палата карары нигезендә яңартылырга мөмкин.

2. Әлеге статья максатларында Иҗтимагый палата составын яңарту дигәндә аның кайбер әгъзалары вәкаләтләренең вакытыннан алдан туктатылуы аңлашыла. Иҗтимагый палатаның составы яңартылуга бәйле рәвештә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла торган әгъзаларының саны Иҗтимагый палата тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә. Шул ук вакытта Иҗтимагый палата әгъзаларының Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, элекке составтагы Иҗтимагый палата тарафыннан расланган исемлекләренең һәркайсы иң күбе дүрттән бер өлешкә үзгәртелә ала.

3. Иҗтимагый палата составын яңарту турында карарны Иҗтимагый палата Советы тәкъдиме буенча, Иҗтимагый палата әгъзаларының эш нәтиҗәлелеген исәпкә алып, Иҗтимагый палата кабул итә. Карарда Иҗтимагый палатаның составы яңартылуга бәйле рәвештә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла торган әгъзалары күрсәтелә.";

8) 13 статьяда:

а) 1 өлештә:

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

"$1^1$) Иҗтимагый палата әгъзасына кагылышлы әлеге Законның $9^1$ статьясы нигезендә вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителсә;";

түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:

"$8^1$) аның кандидатурасын күрсәткән муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы тарафыннан чакыртып алынса;";

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Иҗтимагый палата әгъзасының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, аның кандидатурасын күрсәткән оешма йә аның кандидатурасын күрсәткән

муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы җиде көн эчендә шушы оешмадан йә муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советыннан Иҗтимагый палата әгъзасын раслаган органга яңа кандидатура буенча тәкъдим кертә ала, моңа әлеге статьяның 1 өлешендәге $1^1$, 2, 7, 8 һәм $8^1$ пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча вәкаләтләр туктатылу очраклары керми.";

в) 5 өлештә "оешма" сүзеннән соң ", муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы" сүзләрен өстәргә;

9) 14 статьяда "Оешма" сүзеннән соң ", муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы" сүзләрен, "оешма" сүзеннән соң ", муниципаль берәмлекнең иҗтимагый советы" сүзләрен өстәргә;

10) 15 статьяның 2 өлешендә:

а) "оешмаларның" сүзеннән соң ", муниципаль берәмлекләр иҗтимагый советларының" сүзләрен өстәргә;

б) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11) Иҗтимагый палатаның Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм аларны үстерү турындагы еллык докладын әзерләү һәм бастырып чыгару тәртибе;";

в) түбәндәге эчтәлекле $11^3$ пункт өстәргә:

"$11^3$) Иҗтимагый палата әгъзаларының эш нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары һәм тәртибе;";

11) 16 статьяның 4 өлешендә "кимендә өчтән икесе" сүзләрен "яртысыннан күбрәге" сүзләренә алмаштырырга;

12) 23 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"23 статья. **Иҗтимагый палатаның Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм аларны үстерү турындагы еллык доклады**

1. Календарь ел беткәннән соң Иҗтимагый палата Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм аларны үстерү турында еллык доклад әзерли һәм аны рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгара, шулай ук "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Иҗтимагый палата сайтына урнаштыра.

2. Иҗтимагый палатаның еллык доклады Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелә, шулай ук Иҗтимагый палата карары буенча башка дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына җибәрелергә мөмкин.

3. Иҗтимагый палата рәисе еллык доклад белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында чыгыш ясый.".

**2 статья**

“Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 3 өлеше нигезләмәләренең көче (бу Закон редакциясендә) әлеге Закон үз көченә кергәннән соң Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының беренче ике составы оешканда барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә таралмый.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2015 елның 9 октябре
№ 80-ТРЗ